**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Манзарас авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**3 ноябрь 2021 ел** **№94**

**«Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Кәчимер авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 16 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Кәчимер авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Кәчимер авылы , Таҗетдинов урамы, 36а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында гражданнар җыенын үткәрергә.

2. 2021 елның 16 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Кәчимер авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Кәчимер авылы , Таҗетдинов урамы, 36а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында гражданнар җыенын үткәрергә.

5.Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе (территориаль, вакытлы яки башка билге буенча) муниципаль берәмлек Башлыгының гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарында күрсәтелә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 3 яки күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр яисә ялгыз аналар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Кәчимер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

Кәчимер авылында урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), проект-смета документлары;
- Насослар сатып алу һәм урнаштыру
- Кәчимер авылында энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелек;
- Кәчимер авылы территориясен төзекләндерү;
- Кәчимер авылында юлларны асфальтлау, торбалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясе, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, экспертиза үткәрү;
- Татарстан Кәчимер урамы буенча янгын гидранты һәм комплектлау әйберләре сатып алу һәм урнаштыру, смета документациясе;
- Татарстан Кәчимер ав. Татарстан ур. буенча су белән тәэмин итү системаларын урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документациясе;
- Физкультура һәм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү, спорт чараларын үткәрүне оештыру: булган яссылык спорт корылмаларын карап тоту, күнегүләр оештыру, спорт чараларын әзерләү һәм уздыру өчен белгеч;

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Хәбибуллина